МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан

12.12.2016 № 397

Дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы, аларны биләү коррупция куркынычына бәйле булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен үтәү буенча чаралар хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге УП-636 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-701номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указын үтәү йөзеннән **боерам:**

1. Дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы, аларны биләү коррупция куркынычына бәйле булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының түбәндә теркәлгән
исемлеген расларга (алга таба – Вазыйфалар исемлеге).
2. Кадрлар бүлегенә:

2.1. Әлеге боерыктагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Вазыйфалар исемлеге кергән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә;

2.2. Исемлеккә кергән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә алар эштән азат ителгәндә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсендә каралган чикләүләрне, бурычларны һәм җаваплылыкны аңлатырга.

2.3. Әлеге боерыкны дәүләт теркәве уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Сәгыйтов И.С) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтының «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.
4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланды,
2016 елның «12» декабре.
№ 397

**Дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы, аларны биләү корруцпия куркынычына бәйле булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры;

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы икътисад министры ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркеменең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшләр белән идарә итүче;

Административ реформа мәсьәләләре идарәсе башлыгы;

Территориаль үсеш идарәсе башлыгы;

Инвестицияле һәм инновацияле эшчәнлек идарәсе башлыгы;

Оештыру идарәсе башлыгы;

юридик бүлек башлыгы;

финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы;

кадрлар бүлеге башлыгы;

дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлеге башлыгы;

икътисад һәм социаль өлкә тармаклары үсеше бүлеге башлыгы;

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры урынбасары;

режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр секторы мөдире;

җайлау йогынтысын бәяләү һәм икътисад өчен кадрлар әзерләү секторы мөдире;

юридик бүлек башлыгы урынбасары;

финанс исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы урынбасары;

икътисад һәм социаль өлкә тармаклары үсеше бүлеге башлыгы урынбасары.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

инвестицияле эшчәнлек бүлеге башлыгы;

икътисадый анализ һәм проектлы идарә бүлеге башлыгы;

инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы;

конкуренцияне үстерү бүлеге башлыгы;

муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы;

максатчан программалар бүлеге башлыгы;

лицензияләү бүлеге башлыгы;

кече һәм урта эшкуарлык үсешен анализлау бүлеге башлыгы;

кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлеге башлыгы;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм институтларын үстерү бүлеге башлыгы;

мәгълүматлаштыру бүлеге башлыгы;

административ-хуҗалык бүлеге башлыгы;

инновацияле эшчәнлек бүлеге башлыгы урынбасары;

муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы урынбасары;

максатчан программалар бүлеге башлыгы урынбасары;

конкуренцияне үстерү бүлеге башлыгы башлыгы;

икътисадый анализ һәм проектлы идарә бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

икътисадый анализ һәм проектлы идарә бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

кече һәм урта эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

кече һәм урта эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең әйдәп баруы киңәшчесе;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм институтларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасын үстерү бүлегенең әйдәп баруы белгече;

конкуренцияне үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм институтларын үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече;

кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм институтларын үстерү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.